**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«15» ноябрь, 2022 ел Түбән Суык-Су № 20

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә.

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Дуслык, Заречная, Мазино, Молодежная, Набережная, Новая, Новая Полевая, Полевая, Строителей, Юнусова, 8 Марта урамнарында 2022 елның 25 ноябренә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Остров, Центральная, Школьная, Парковая, им.Г.Тукая, им.М.Ждалиля, Садовая, Солнечная, Татарстан, Тынычлык, Успешная, Цветочная, Яшьлек, 70 лет Победы, Дружбы, Камышлы урамнарында 2022 елның 25 ноябренә 16.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Түбән Суык-Су авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен

киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу.
- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү.
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу.
- Су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре).
- Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту).
- Күлне камышлардан чистарту.
- Зиратны төзекләндерү (материаллар сатып алу, койма ясау һәм урнаштыру).
- Янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә).
- Белорус тракторына җиһазлар (чапкыч, отвал, щетка) сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Түбән Суык-Су авылы, Үзәк урам, 1А йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1639032343